Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Арча муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Арча муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-12-35

**КАРАР**

**“ 19 ” октябрь 2017 ел** **№ 3**

**Төзекләндерү кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон, « Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы,

«Арча шәһәре» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә нигезендә, Арча шәһәр Советының 07.2009 № 426 карары ( 25.04.2011№ 15, 10.02.2012№ 38 үзгәрешләре белән) нигезендә, "Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге халкының муниципаль хокукый актлар проектлары турында фикер алышуда катнашу хокукын тәэмин итү максатларында карар бирәм:

1. «Арча шәһәре муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләре проекты турында» Арча шәһәр Советы карары проекты буенча гавами тыңлауларны 30.10.2017 елга билгеләргә.

2. «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләре проекты турында Арча шәһәр Советы карары проекты буенча гавами тыңлауларны 16.00 сәгатьтә ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт адресы буенча үткәрергә.

3. «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләренә тәкъдим ителгән үзгәрешләр буенча гражданнар тәкъдимнәре, кисәтүләре һәм гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар 30.10.2017 елда 17.00 сәгатькә кадәр язмача түбәндәге адрес буенча җибәрелә дип билгеләргә: ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт, тел.884366 3 16 25.

4. Төзекләндерү кагыйдәләре проекты турында Арча шәһәр Советының әлеге карарын һәм карар проектын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә «Арча хәбәрләре» газетасында, Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе Р. Ф. Касыймовка йөкләргә

« Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе

И.Г. Нур ев